ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Оешмалар мөлкәтенә салым турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Оешмалар мөлкәтенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $1^1$ статьяның 1 өлешендә “3000” саннарын “2000” саннарына алмаштырырга;

2) 2 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Салым базасы кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә торган күчемсез мөлкәт объектларына карата салым ставкасы 2015 һәм 2016 елларда – 1,2 процент, 2017 елда – 1,5 процент, 2018 елда – 1,8 процент, 2019 елда һәм аннан соңгы елларда 2 процент күләмендә билгеләнә.”;

3) 3 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:
“10) полиальфаолефиннар һәм алар нигезендә синтетик, ярымсинтетик мотор майлары җитештерүче оешмаларга карата, алар җитештергән полиальфаолефиннарны һәм синтетик, ярымсинтетик мотор майларын реализацияләүдән керем оешманың салым (хисап) чорында алынган керемнәренең гомуми суммасында кимендә 70 процентны тәшкил итү шарты белән.”;

4) 5 статьяның 3 пунктында “1 өлешенең 10 пунктын” сүзләреннән соң “2 өлешенең 10 пунктын” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2016 елның 1 гыйнварыннан, әмма басылып чыккан көненнән соң кимендә бер ай узгач, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 25 сентябре
№ 62-ТРЗ